ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**КАРАР**

**« 02 » декабрь 2020 ел** **№ 20**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 августындагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чуриле авыл җирлеге башкарма комитетының «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 августындагы 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Административ регламентның 1.5 пунктының 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"адрес бирү объектының тәңгәлләштерү элементлары" - җир кишәрлекләренең номерлары, башка адрес бирү объектларының типлары һәм номерлары;

2) «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» дигән икенче бүлекнең 2.5, 2.6 пунктларын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Чуриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Хидиятуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Иске Чуриле авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.12.2020 ел, № 20 карарына
кушымта

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.5. Законнар яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле муниципаль хезмәтне, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны күрсәтү тәртибе | 1) Гариза:<br>- документ формасында язмача кәгазьдә;<br>-Региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (1 нче кушымта);<br>2) шәхесне раслый торган документлар;<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта).<br>4) адрес бирелә торган объектка (объектларга) хокук билгели һәм (яисә) хокук таныклый торган документлар (бинага (төзелеш) яки корылмага адрес бирелгән очракта, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, аларны төзү өчен төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган төзелеш эшләре тәмамланмаган объектларга, әлеге бина (төзелеш), корылма урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели һәм (яисә) хокук раслый торган документлар)<br>5) аларны үзгәртеп кору нәтиҗәсендә бер һәм аннан да күбрәк санда адрес бирү объекты барлыкка килгәндә, күчемсез милек объектлары турында күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектларын үзгәртеп корганда, яңа бер яки аннан да күбрәк адрес бирү объектлары барлыкка килгән очракта); | РФ Хөкүмәтенең 19.11.2014 ел № 1221 карары белә расланган адресларны биру үзгәртү һәм юкка чыгар Кагыйдәләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) адрес бирү объектын төзүгә рөхсәт (төзелеп яткан объектка адрес биргәндә), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бинаны (төзелешне) төзү яки үзгәртеп кору өчен корылманы төзүгә рөхсәт алу таләп ителмәү очрагыннан тыш, һәм (яисә) адрес бирү объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт булганда;<br>7) адрес бирү объектының кадастр планында яки тиешле территориянең кадастр картасында урнашу схемасы (җир кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);<br>8) адрес бирү объекты булып торган күчемсез милек объекты турында күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (кадастр исәбенә куелган адрес объектына адрес бирелгән очракта);<br>9) бер һәм аннан да күбрәк яңа адрес бирү объекты барлыкка китерә торган бинаны үзгәртеп корганда һәм (яки) яңадан планлаштырганда, кабул итү комиссиясе акты (бер яки аннан да күбрәк яңа адрес бирү объекты барлыкка килгән күчемсез милек объектларын (биналарны) үзгәртеп корган очракта);<br>10) адрес бирү объекты булып торган күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адрес бирү объектының адресын гамәлдән чыгару очрагында);<br>11) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан адрес бирү объекты булган күчемсез милек объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адрес бирү объектының адресын гамәлдән чыгару очрагында).<br>Мөрәҗәгать итүчеләр (мөрәҗәгать итүченең вәкилләре) гариза биргәндә, әгәр әлеге документлар дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булмаса, югарыда күрсәтелгән документларны теркәргә хокуклы. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Кагыйдәләрнең 34 пунктындагы "б", "д", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән документлар вәкаләтле орган соратуы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.<br>Кагыйдәләрнең 34 пунктының "а", "в", "г", "е" һәм "ж" пунктчаларында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән раслана, аның төре "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 211 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын, шәхси мөрәҗәгать итеп, Башкарма комитетта алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аның белән бергә тапшырыла торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен сайлап, язмача тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);<br>почта аша теркәлгән документлар исемлеге һәм тапшыру турында хәбәрнамә белән.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документлар электрон документлар рәвешендә гариза бирүче тарафыннан Региональ портал аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы | Ведомствоара бәйләнеш кысаларында алына:<br>1) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан һәркем ала алырлык мәгълүматлар тупланган күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында өземтә;<br>2) күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан төп характеристикалар һәм күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында өземтә; | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан алу, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар аларның карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | 3) җирле үзидарә органының торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинаны торак бинага күчерү турында карары (торак бинадан торак булмаган бинага яки торак булмаган бинадан торак бинага күчерү нәтиҗәсендә бинага адрес бирелгән, үзгәртелгән һәм гамәлдән чыгарылган очракта);<br>4) Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адрес бирү объекты адресын гамәлдән чыгарган очракта, төп характеристикалар һәм күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (14 пунктның " а " пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча);<br>5) күчемсез милекнең бердәм дәүләт кадастрында адрес бирү объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресы юкка чыгарылган очракта);<br>Кагыйдәләрнең 34 пунктындагы "б", "д", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән документлар вәкаләтле орган соратуы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тапшырыла.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |